РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НУРЛАТСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ГЛАВА АХМЕТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ӘХМӘТ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Әхмәт ав. КАРАР

2 ноябрь 2020 ел № 3

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге Чуаш Мәнҗесе авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законның 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елның 12 ноябрендә 9 сәгать 00 минутка Чуаш Мәнҗесе авылы, Шоссе урамы, 25а адресы буенча урнашкан ФАП бинасы янында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Чуаш Мәнҗесе авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Чуаш Мәнҗесе авылының Шоссе, Полевая урамнарындагы йортларда яшәүчеләр өчен Халык җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2020 елның 12 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Чуаш Мәнҗесе авылы, Шоссе урамы, 25а адресы буенча урнашкан ФАП бинасы янында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Чуаш Мәнҗесе авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Чуаш Мәнҗесе авылының Мәктәп, Үзәк урамнарындагы йортларда яшәүчеләр өчен Халык җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2020 елның 12 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Чуаш Мәнҗесе авылы, Шоссе урамы, 25а адресы буенча урнашкан ФАП бинасы янында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Чуаш Мәнҗесе авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Чуаш Мәнҗесе авылының Садовая, Дорожная, Бригада урамнарындагы йортларда яшәүчеләр өчен Халык җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.

4. 2020 елның 12 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка Чуаш Мәнҗесе авылы, Лермонтов урамы, 18нче йорт адресы буенча урнашкан йорт янында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Чуаш Мәнҗесе авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Чуаш Мәнҗесе авылының Лермонтов, Хәй Яһүдин исемендәге урамнардагы йортларда яшәүчеләр өчен Халык җыенының дүртенче этабын уздыруны билгеләргә.

5. Гражданнар җыенын уздыру өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

5. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

6. Гражданнар җыенына чыгарылучы сорауны расларга:

«2021 елда Нурлат муниципаль районының Әхмәт авыл җирлеге Ерепкино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, бачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, сугышчан хәрәкәтләр ветераннары, 75 яшьтән өлкәнрәк ялгыз яшәүче гражданнардан кала, һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Чуваш Мәнҗесе авылы чикләрендә җирлек эчендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту;

- МТЗ-82 тракторына асылмалы җиһазлар сатып алу;

- Чуаш Мәнҗесе авылында җәяүлеләр күперен ремонтлау.

« РИЗА» «КАРШЫ».

8. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чуаш Мәнҗесе авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Әхмәт авыл җирлеге башлыгы Р.Х. Шәйхетдинов